СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп урамы. 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru.

**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**26 январь 2016 ел** **№ 16**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2016 елның 22 гыйнварындагы Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә Шушмабаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартына Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2016 елда Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) һәм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү | - Илдус, Угез-Елга авыллары өчен янгын сүндерү сыешлыклары сатып алу ; янгын сүндерү гидранты | 20000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | урнаштыру. | |
| 2 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - Шушмабаш авылында су скважинасы бораулау,<br>- Шекә авылында суүткәргеч челтәр сузу; | 60000<br>20000 |
| 3 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Шушмабаш авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда юлларны вак таш-лау; | 335490 |
| 4 | Җирлек территория-сен төзекләндерүне оештыру | - Шушмабаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктлар өчен аншлаглар әзерләү . | 9460 |
| 5 | Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыру | - вакытлыча корыла торган урыннарны тоту, Шушмабаш авыл җирлеге составына керә торган барлык торак пунктларда каты коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгаруны оештыру; | 10000 |
| | | Барлыгы: | 454950 |

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп ур., 1б йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Носы авылы, Татарстан ур., 45 йорт.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" ОГРН 1121690009210 ИНН 1609012678